РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет Янгасалского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Янасала авыл жирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, 1, с.Большая Янгасала, 422832
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22

Центральная урамы, 1,Янасала авылы, 422832,
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22

ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 1622004588/162201001

ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 1622004588/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31 гыйнвар 2023ел** **№ 1**

**"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районыны Яңасала авыл җирлегендә 2023 елда җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында"**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турындагы «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы “2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында "гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварендагы 1 нче номерлы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасл авыл

җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында " Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Яңасала авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И. Х. Шиһабеев**

Кама-Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче номерлы кушымта
31.01.2023 № 1

**Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Наименование услуг** | **Стоимость услуг *(в руб.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен мөһим башка предметларны бирү һәм китерү | 4670,06 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 664,55 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2458,87 |
| **Барлыгы** | 7793,48 |

Кама-Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 2 нче номерлы кушымта
31.01.2022 № 1

**Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Тәнне төрү | 239,67 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен мөһим башка предметларны бирү һәм китерү | 4430,39 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 664,55 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2458,87 |
| **Барлыгы** | 7793,48 |